| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.04.2017 Казан шәһәре № под-691/17

«Иң яхшы методист» гранты турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый усеш стратегисен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын раслау турында» 2015 елның 25 сентябрендәге 707 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы муниципальберәмлекләре мәгариф бүлекләре (идарәләре) башлыкларының укыту-методик һәм тәрбия эшләре буенча иң яхшы урынбасарларын, методистларны ачыклау һәм стимуллаштыру, аларның потенциалын үстерү юлы белән гомуми белем бирүнең сыйфатын күтәрү максатында б о е р а м:

1. «Иң яхшы методист» грантын гамәлгә куярга.

2. «Иң яхшы методист» гранты турында тәкъдим ителгән Положениене расларга.

2.2. «Иң яхшы методист» грантын гамәлгә ашыру чараларының (алга таба-Чара) календарь планын расларга.

3.Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм Чараны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларга әлеге боерыкның 2.2. пункты белән расланган план үтәлешен тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү» институты өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениясенә (Р.Р.Бәдриевага) «Иң яхшы методист» грантын методик яктан тәэмин итәргә;

5 Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г. К. Мөхәммәдкәримовага) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган тәртиптә, башка бюджеттан тыш трансфертлар рәвешендә алу өчен, конкурста җиңүчеләргә грантлар түләүгә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә акча күчерү эшен оештырырга.

6. Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестациясе бүлегенә (Л.И.Сәүбәновага) боерык кабул ителгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә, аны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә (юлларга).

7. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Иң яхшы методист» гранты турында» 2016 елның 20 июлендәге под -1230/16 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

8. Боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары - министр Э.Н.Фәттахов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
2017 елның 20 апрелендә № под-691/17
боерыгы белән

“ Иң яхшы методист “ гранты турында
Положение

1. Гомуми положениеләр

1.1. «Иң яхшы методист» гранты (алга таба – Грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - Министрлык) боерыгы белән гамәлгә куела.

Грант Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең иң яхшы методистларын, мәгариф бүлекләре (идарәләре) башлыкларының укыту-методик яки тәрбия эше буенча урынбасарларын ачыклау, аларның эшчәнлекләрен стимуллаштыру һәм иҗади потенциалын үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

Грантның төп максатлары булып тора:

үз эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешүгә мотивлаштырылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең иң яхшы методистларын, мәгариф бүлекләре (идарәләре) башлыкларының укыту-методик яки тәрбия эше буенча урынбасарларын ачыклау хисабына Татарстан Республикасында белем бирү сыйфатын күтәрү;

методист хезмәтенең дәрәҗәсен күтәрү.

1.2. Грант алуга конкурста муниципаль берәмлекләрдәге мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре эшчәнлеген мәгълүмати-методик яктан тәэмин итүче,Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф бүлекләре (идарәләре) методистлары, башлыкларның укыту-методик эш буенча яки Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф бүлекләре (идарәләре) башлыкларының тәрбия эше буенча урынбасарлары катнаша ала.

Чарада грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) һәм грант алучы катнаша.

Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) - грантлар бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Министрлык.

Грант алучы – агымдагы Положениедә билгеләнгән критерий һәм таләпләргә туры килгән, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге мәгариф бүлеге (идарәсе) башлыгының уку-методик яки тәрбия эше буенча урынбасары, методисты булып торган, «Иң яхшы методист» грантын алуга Республика конкурсын үткәрү нәтиҗәләре турында»Министрлык боерыгын бастырган вакытта әлеге эшчәнлекне дәвам итүче, конкурс сайлап алуын узган физик зат.

Грант алучыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү грант булып тора:

1дән 25кә кадәр урын алган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре мәгариф бүлекләре (идарәләре) башлыкларының укыту-методик эш буенча урынбасарларына 50 000 (илле мең) сум күләмендә;

1дән 25кә кадәр урын алган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре мәгариф бүлекләре (идарәләре) башлыкларының тәрбия эше буенча урынбасарларына 50 000 (илле мең) сум күләмендә;

1дән 280гә кадәр урын алган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бүлек (идарә) методистларына 130 000 (йөз утыз мең) сум күләмендә.

1.3. Грантта катнашу өчен гаризада соңгы 3 елдагы һөнәри казанышлар нәтиҗәләре турында мәгълүматлар тапшырырга кирәк (ә 2016 елда «Иң яхшы методист» грантын алучыларга соңгы ел эчендә).

1.4. Грант алырга теләүчеләрне конкурслы сайлап алу әлеге Положениедә билгеләнгән тәртиптә ике этапта үткәрелә. Беренче этапта документаль конкурс сайлап алуы гамәлгә ашырылачак, аның нәтиҗәләре буенча икенче этап үткәреләчәк - күзгә-күз сөйләшүләр алып барылачак. Сайлап алуны Министрлык тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3 бүлеге нигезендә төзелгән грантны гамәлгә ашыру буенча республика Эксперт комиссиясе уздыра.

1.5. Грант алуга дәгъва кылучыларның документаль конкурслы сайлап алуның бәяләү критерийлары булып тора:

Башлыкларның укыту-методик эш буенча урынбасарлары өчен:

муниципаль берәмлектәге педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санынннан квалификацион категориягә ия булган педагогик хезмәткәрләрнең өлеше;

бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллы;

муниципаль берәмлектәге чыгарылыш сыйныф укучыларының гомуми саныннан, иң түбән бусаганы узмаган 11 сыйныф укучыларының өлеше;

Бөтенроссия олимпиадаларының республика этапларында һәм төбәк этабында җиңүчеләр, призерлар саны үзгәрү динамикасы;

Педагогик хезмәткәрләрнең муниципаль, республика күләмендәге һәм һөнәри осталык конкурсларындагы казанышларының саны үзгәрү динамикасы;

муниципаль берәмлектә педагогик хезмәткәрләрнең гомуми саныннан вакытында квалификацияне күтәрүне узган педагогик хезмәткәрләренең өлеше;

республика, федераль һәм халыкара проектларны гамәлгә ашыру материаллары (белем бирү эксперименты, инновацион мәйданчыклар) булу;

эшчәнлек нәтиҗәләре буенча методик рекомендацияләр, аналитик материаллар, мәгълүмати-диагностика җыентыкларын бастырып чыгару;

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри компетентлыгы (осталыгы) үсешен методик яктан тәэмин итү (семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглар оештыру һәм үткәрү);

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри конкурсларда катнашуын методик яктан тәэмин итү (педагогик хезмәткәрне әзерләү һәм озата бару);

мәгариф учреждениеләрендә инновацион проектлар һәм программаларны тормышка ашыруны методик яктан тәэмин итү;

педагогик хезмәткәрләргә укучыларның иҗади потенциалын һәм сәләтен үстерүдә методик ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмалар модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта аша эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарда, берләшмәләрдә катнашу);

Башлыкларның тәрбия эше буенча урынбасарлары өчен:

муниципаль берәмлекнең белем бирү оешмаларындагы укучыларның гомуми саныннан балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядә, хокук саклау органнарында яки мәктәп эчендә учетта торучы укучыларның өлеше;

белем алучылар тарафыннан кылынган хокук бозулар саны динамикасы;

муниципаль белем бирү оешмаларында психологик-педагогик хезмәт эшенең нәтиҗәлелеге;

мәгариф оешмаларының наркотикларга каршы республика чараларында, проектларда катнашуы;

сәламәтлеккә ярдәм итүче мәктәпләр челтәрен үстерү динамикасы;

физкультура-сәламәтләндерү һәм массакүләм спорт эшенең иң яхшы куелышына муниципаль берәмлекләр рейтингы нәтиҗәләре буенча спорт-сәламәтләндерү эшен оештыру;

өстәмә белем бирү программасы буенча шөгыльләнүче контингентның сакланышы;

муниципаль берәмлектәге педагогик хезмәткәрләрнең гомуми саныннан мәгариф оешмаларының аттестация узган педагогик хезмәткәрләренең өлеше;

сыйныф җитәкчеләренең, гомуми белем бирү оешмаларының тәрбия эше буенча директор урынбасарларының, өстәмә белем бирү педагогик хезмәткәрләренең һөнәри компетентлыгын үстерүдә методик ярдәм күрсәтү (семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглар һ.б.);

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри конкурсларда катнашуын методик яктан тәэмин итү (педагогик хезмәткәрне әзерләү һәм озата бару);

мәгариф оешмаларында тәрбия эшенең инновацион проектларын һәм программаларын тормышка ашыруны методик яктан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмаларны модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта аша эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарда эшләү, бедәмлекләрдә катнашу);

башлангыч белем бирү буенча методистлар өчен:

муниципаль берәмлектә педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санынннан квалификацион категориягә ия  булганпедагогик хезмәткәрләрнең өлеше;

дүртенче сыйныфларда рус теле һәм математика буенча мониторинг тикшеренүләренең уртача баллы;

республика, федераль олимпиадаларда, конкурсларда җиңүчеләрнең, призерларның саны үзгәрү динамикасы;

муниципаль, республика һәм һөнәри осталык конкурсларында педагогик хезмәткәрләрнең казанышлары (бүләкләре, грантлар) саны үзгәрү динамикасы;

муниципаль берәмлектәге педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санынннан квалификацияне вакытында күтәрүне узган педагогик хезмәткәрләрнең өлеше;

республика, федераль һәм халыкара проектларны гамәлгә ашыру материаллары (белем бирү эксперименты, инновацион мәйданчыклар) булу;

эшчәнлек нәтиҗәләре буенча методик рекомендацияләр, аналитик материаллар, мәгълүмати-диагностика җыентыкларын бастырып чыгару;

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри компетентлыгын (осталыгын) үстерүдә методик ярдәм күрсәтү (семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглар һ.б.);

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри конкурсларда катнашуын методик яктан тәэмин итү (педагогик хезмәткәрне әзерләү һәм озата бару);

мәгариф оешмаларында инновацион проектлар һәм программаларны тормышка ашыруны методик яктан тәэмин итү;

педагогик хезмәткәрләргә укучыларның иҗади потенциалын һәм сәләтен үстерүдә  методик ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмалар модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта аша эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарда эшләү, бердәмлекләрдә катнашу);

мәгариф өлкәсендә максатчан программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыру буенча өлкән методистлар өчен:

мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри компетентлыгын үстерүдә методик ярдәм күрсәтү нәтиҗәлелеге (методик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру):семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглар һәм башкалар);

эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату (чыгышлар, чыгыш ясаучыны әзерләү, үз мәкаләләреңне һәм/яки сататьяләреңне бастырып чыгару, педагогик хезмәткәрләр, методистлар һәм җитәкчеләрнең бастырылып чыккан статьялары һәм/яки мәкаләләре белән эшләү);

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри конкурсларда һәм грантларда катнашуына методик ярдәм күрсәтүне оештыру;

мәгариф оешмаларында инновацион проектларны һәм программаларны тормышка ашыруны методик яктан тәэмин итү (мәгариф оешмаларын мәгълүмат белән тәэмин итү, аңлату һәм җәлеп итү, гаризалар рәсмиләштерү, методик ярдәм һ.б..);

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмаларны модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарда эшләү, бердәмлекләрдә катнашу);

мәгълүмати технологияләр һәм интерактив укыту чаралары буенча методистлар өчен:

белем бирү эшчәнлеген контрольдә тоту, диагностика һәм мониторинглауның инновацион электрон формаларын һәм укытуның интерактив чараларын кулланышка кертү;

мәгълүмати технологияләр;не һәм интерактив укыту чараларын куллану буенча Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә кертү нәтиҗәләрен диагностикалау һәм мониторинглауны оештыру, үткәрү;

1Т-чемпион конкурсында ирешкән казанышлар саны үзгәрү динамикасы;

педагогик хезмәткәрләрнең мәгълүмати-коммуникацион технологияләр (алга таба - ИКТ) буенча конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә, шул исәптән дистанцион рәвештә катнашуы;

мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренең ИКТ-компнтентлылыгы: мәгълүмати технологияләр, интерактив укыту чаралары, дистанцион укыту формалары үсешенең уңай динамикасы;

ИКТ өлкәсендә педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү һәм тарату;

мәгариф процессында катнашучыларның челтәрле хезмәттәшлеген координацияләү;

педагогик хезмәткәрләрнең ИКТ-компетентлыгы үсешен методик яктан тәэмин итүне (семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, тестлар үткәрү, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглар һ.б. оештыру һәм үткәрү);

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри конкурсларда, чараларда катнашуын тәэмин итү (конкурста катнашучы педагогларга веб-ресурслар эшләүдә, аларны тулыландыруда һәм алып баруда ярдәм итү);

белем бирү процессында катнашучыларның төрле дәрәҗәдәге мәгълүмати белем бирү ресурсларыннан файдалана алуын оештыру (район һәм/яки шәһәрнең веб-ресурсларын мәгълүмат белән тулыландыру һәм алып бару, ведомство карамагындагы белем бирү оешмаларының электрон журналларын, көндәлекләрен һәм сайтларын тутыру мониторингы, электрон почта, мәгълүматларның электрон базасын алып бару һ.б.)

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмаларны модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта аша эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарда эшләү, бердәмлекләрдә катнашу);

милли мәгариф буенча методистлар өчен:

бердәм республика имтиханнарының уртача баллы, бердәм республика тестының уртача билгесе;

муниципаль берәмлектәге укучыларның гомуми саныннан туган (татар) телендә укучыларның өлеше;

муниципаль берәмлектә туган тел укытучыларының гомуми саныннан беренче һәм югары квалификация категориясенә ия булган туган тел укытучыларының өлеше;

муниципаль берәмлектә туган тел укытучыларының гомуми саныннан үз фәне буенча курс әзерлеген вакытында узган туган тел укытучыларының өлеше;

республика олимпиадаларында, конкурсларда җиңүчеләр саны үзгәрү динамикасы;

муниципаль, республика, федераль һөнәри осталык конкурсларында казанышлар (бүләкләр, грантлар) саны үзгәрү динамикасы;

педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү һәм тарату (басма хезмәтләр, материалларны сайтка урнаштыру, шул исәптән Belem.ru сайтына, семинарлар, мастер-класслар, түгәрәк өстәлләр үткәрү, чыгышлар ясау);

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри компетентлыгы үсешен методик яктан тәэмин итү (семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглары оештыру һәм үткәрү);

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри конкурсларда катнашуын методик яктан тәэмин итү (педагогик хезмәткәрне әзерләү һәм озата бару);

мәгариф учреждениеләрендә инновацион проектлар һәм программаларны тормышка ашыруны методик яктан тәэмин итү;

педагогик хезмәткәрләргә укучыларның иҗади потенциалын һәм сәләтен үстерүдә методик ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмаларны модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта аша эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарда эшләү, бердәмлекләрдә катнашу);

мәктәпкәчә тәрбия буенча методистлар өчен:

муниципаль берәмлектәге мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренең гомуми саныннан мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының квалификация категориясенә ия булган педагогик хезмәткәрләренең өлеше;

муниципаль берәмлектәге мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренең гомуми санынннан үз вакытында квалификацияләрен күтәрүне узган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренең өлеше;

мәктәпкәчә белем бирү оешмалары арасында республика конкурсларында җиңүчеләр, грант алучылар саны үзгәрү динамикасы;

муниципаль, республика, федераль һөнәри осталык конкурсларында педагогик хезмәткәрләрнең ирешкән уңышлары (бүләкләре, грантлар) үзгәрү динамикасы;

муниципаль, республика, федераль һәм халыкара проектлар материаллары (эксперименталь, инновацион мәйданчыклар) булу;

эшчәнлек нәтиҗәләре буенча методик рекомендацияләр, аналитик материаллар, мәгълүмати-диагностика җыентыклары бастырып чыгару;

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри компетентлыгын үстерүдә методик ярдәм күрсәтү (семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглар h.б.);

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри конкурсларда катнашуын методик яктан тәэмин итү (педагогик хезмәткәрне әзерләү һәм озата бару);

мәгариф оешмаларында инновацион проектлар һәм программаларны тормышка ашыруны методик яктан тәэмин итү;

педагогик хезмәткәрләргә укучыларның иҗади потенциалын һәм сәләтен үстерүдә методик ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмаларны модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта аша эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарда эшләү, бердәмлекләрдә катнашу);

белем бирү процессын ресурслар белән тәэмин итү буенча методистлар өчен:

белем бирү оешмаларының уку-укыту комплектлары белән тәэмин ителешен конртрольдә тотуда, диагностикалау һәм мониторинглауда инновацион электрон формаларны кертү һәм куллану;

федераль дәүләт белем бирү стандартларын кертүне ресурслар белән тәэмин итү диагностикасы һәм мониторингын оештыру һәм үткәрү;

мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләрен укучыларның төрле категорияләренә исәпләнгән белем бирү программалары, дәреслекләр һәм укыту-методик басмалар белән тәэмин итү;

китапханә хезмәткәрләренең конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә, шул исәптән дистанцион бәйгеләрдә катнашу нәтиҗәләре буенча призлы урыннар булуы;

муниципаль берәмлектә китапханә хезмәткәрләренең гомуми саныннан квалификация күтәрү курсларын узган белем бирү оешмалары китапханә хезмәткәрләренең өлеше;

муниципаль берәмлектә китапханә хезмәткәрләренең гомуми саныннан ИКТ-компетентлыгы булган мәгариф оешмалары китапханә хезмәткәрләренең өлеше;

китапханә тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату;

мәгариф оешмаларын китапханә һәм мәгълүмати-библиографик ресурс чаралары белән тәэмин итү динамикасы;

педагогик хезмәткәрләр һәм китапханәчеләрнең һөнәри компетентлыгын үстерүдә методик ярдәм күрсәтү (семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглар һ.б.);

педагог-китапханәчеләрнең һөнәри конкурсларда катнашуын методик яктан тәэмин итү (педагогик хезмәткәрне әзерләү һәм озата бару);

мәгариф учреждениеләрендә инновацион проектлар һәм программаларны тормышка ашыруны методик яктан тәэмин итү;

укучыларның уку культурасын үстерүдә китапханәчеләргә методик ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмаларны модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта аша эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарда эшләү, Бөтенроссия методик берләшмәләрдә һәм берләшмәләрдә катнашу);

белем бирү оешмаларының укыту әдәбияты белән тәэмин ителеше;

белем бирү процессын ресурслар белән тәэмин итүне оештыру (дәреслекләр кабул итүне оештыру, дәреслекләр бүлү һәм тарату, финанс хисаплылыгы (разнарядкалар,хисап кәгазьләрен бухгалтерия белән чагыштыру);

уку дисциплиналары буенча методистлар өчен:

муниципаль берәмлектә педагогик хезмәткәрләрнең гомуми саныннан квалификацион категориягә ия булган педагогик хезмәткәрләрнең өлеше;

методист карамагындагы фәннәр буенча бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллы;

муниципаль берәмлектә чыгарылыш сыйныф укучыларының гомуми саныннан методист кармагындагы фәннәр буенча иң түбән бусаганы узмаган 11 сыйныф укучыларының өлеше;

методист уарамагындагы фәннәр буенча Бөтенроссия олимпиадаларының республика һәм төбәк этапларындада җиңүчеләр, призерлар саны үзгәрү динамикасы;

муниципаль берәмлектә педагогик хезмәткәрләрнең гомуми саныннан методист карамагындагы фәннәр буенча үз вакытында квалификацияне күтәрүне узган педагогик хезмәткәрләрнең өлеше;

республика, федераль һәм халыкара проектларны гамәлгә ашыру материаллары (белем бирү эксперименты, инновацион мәйданчыклар) булу;

эшчәнлек нәтиҗәләре буенча методик рекомендацияләр, аналитик материаллар, мәгълүмати-диагностика җыентыклары бастырып чыгару;

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри компетентлыгы үсешен методик яктан тәэмин итү (семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглар оештыру һәм үткәрү);

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри конкурсларда катнашуын методик яктан тәэмин итү (педагогик хезмәткәрне әзерләү һәм озата бару);

мәгариф учреждениеләрендә инновацион проектлар һәм программаларны тормышка ашыруны методик яктан тәэмин итү;

педагогик хезмәткәрләргә укучыларның иҗади потенциалын һәм сәләтен үстерүдә методик ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмаларны модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта аша эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарда эшләү, бердәмлекләрдә катнашу);

Кадрлар эше һәм педагогик кадрларны аттестацияләү методистлары өчен:

муниципаль берәмлектә педагогик хезмәткәрләрнең квалификация дәрәҗәсе;

муниципаль берәмлектәге җитәкче һәм педагогик кадрларының гомуми саныннан квалификация күтәрү курсларын узган җитәкче һәм педагогик кадрларның өлеше;

муниципаль берәмлектәге җитәкче һәм педагогик кадрларының гомуми саныннан һөнәри яктан яңадан әзерлек үткән җитәкче һәм педагогик кадрларның өлеше;

муниципаль берәмлектәге педагогик хезмәткәрләрнең гомуми саныннан беренче квалификация категориясенә ия булган педагогик хезмәткәрләрнең өлеше;

муниципаль берәмлектәге педагогик хезмәткәрләрнең гомуми саныннан югары квалификация категориясенә ия булган педагогик хезмәткәрләрнең өлеше;

муниципаль берәмлектәге педагогик хезмәткәрләрнең гомуми саныннан биләгән вазыйфасына туры килүен раслау максатында аттестация узган педагогик хезмәткәрләрнең өлеше;

җитәкче һәм педагогик кадрларның алдынгы педагогик тәҗрибәсен муниципаль берәмлектә тарату;

мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри компетентлыгын үстерүдә методик ярдәм күрсәтү (семинарлар, практикумнар, методик коучинглар, инструктив-методик киңәшмәләр, мастер-класслар, тренинглар һ.б.);

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында челтәрле хезмәттәшлек (блогларда язмаларны модельләштерү, педагогик хезмәткәрләр белән электрон почта аша эшләү, шәхси блог һәм/яки шәхси сайт алып бару, форумнарда һәм вебинарларда эшләү, берләшмәләрдә катнашу).

1.6. Грант алырга теләүчеләр Татарстан Республикасы мәгариф идарәсе муниципаль органының штат хезмәткәре булырга тиеш.

1.7. Конкурста катнашучы кешеләрнең яше чикләнмәгән. Педагогик стажы 3 елдан да ким булмаска тиеш.

1.8. Грант алырга теләүчеләрне конкурслы сайлап алу 2017 елның 15 маеннан 30 июненә кадәр әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртип һәм сроклар нигезендә үткәрелә.

1.9. Грант алучылар эксперт комиссиясе тарафыннан билгеләнә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

1.10. Грант бирү турындагы карар грант алуга конкурста катнашу вакытында һәм грантны гамәлгә ашыру чорында дәгъва кылучы турында белә торып дөрес булмаган яки ялган белешмәләр ачыклаганда кабул ителми.

1.11. Грант алуга конкурс турында мәгълүмат (шартлар, таләпләр конкурсны үткәрү сроклары) "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.

## 2. Грант алуга конкурста катнашу өчен гариза бирү

2.1. Грант алырга теләүчегә, 2017 елның 31 маеннан да соңга калмыйча, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты «дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесенең (алга таба – ТР Мәгарифне үстерү институты) рәсми сайты (http://www.irort.ru «Укытучыларга грантлар» бүлеге, «Иң яхшы методист» бите) аша гариза бирергә кирәк

2.2. Гаризаны 2017 елның 31 маеннан соң тапшырган очракта, грантка дәгъва кылучы конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

2.3. "ТР Мәгарифне үстерү институты"на бирелгән материалларны анализлау нәтиҗәләре буенча, әлеге Положениенең таләпләренә туры килә торган гаризалар сайлап алына һәм, киләчәктә карау өчен, эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта, эксперт комиссиясенә тапшырыла.

## 3. Конкурсны үткәрү тәртибе

3.1. Грант алуга Конкурс Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә.

3.2. Грант бирүче, гаризалар кабул итү срогы тәмамланганчы, 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, “Иң яхшы методист” гранты турында” боерыгын Министрлыкның рәсми сайтында (http://mon.tatarstan.ru) урнаштыра.

3.3. Конкурс материалларын бәяләү өчен составында рәис һәм комиссия әгъзалары булган 10 кешедән торган Эксперт комиссиясе төзелә.

3.4. Эксперт комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

3.5. Конкурс материалларына экспертиза уздырганда, Эксперт комиссиясендә эшләргә бәйсез экспертлар җәлеп ителә ала.

3.6. Экспертлар сыйфатында:

Министрлык;

педагогик хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белем бирү төбәк оешмалары;

югары һөнәри белем бирү оешмалары;

җәмәгатьчелек вәкилләре җәлеп ителергә мөмкин;

3.7. Конкурс материалларын экспертизалаганда:

тәкъдим ителгән материалларны бәяләү критерийлары нигезендә бәяләүнең объективлыгы;

конфиденциальлеге саклана.

3.8. 2017 елның 15 июненә кадәр эксперт комиссиясе грант алырга теләүчеләр биргән документларга, әлеге Положение нигезендә билгеләнгән критерийларга туры китереп, алдан якынча экспертиза уздыра:

һәр критерий буенча Эксперт комиссиясе әгъзасы грант алырга теләүчегә 1дән 5 кә кадәр балл бирә, конкурс сайлап алуының һәр критериясе буенча максималь балл-5 балл;

баллар эксперт битләренә кертелә, Эксперт комиссиясе әгъзасы имзасы белән раслана һәм Эксперт комиссиясе рәисенә тапшырыла;

эксперт битләре нигезендә грант алырга теләүчеләрнең рейтингы формалаша (төзелә).

Баллар тигез күләмдә булса, Эксперт комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

3.9. Тәкъдим ителгән материалларны анализлау нәтиҗәләре буенча, сайлап алуның көндезге этабында эксперт комиссиясе тарафыннан алга таба карау өчен, документлары әлеге Положение таләпләренә туры килә торган дәгъва кылучылар сайлап алына.Көндезге этап комиссия рәисе раслаган график буенча 2018 елда 19нан 23 июньгә кадәр узачак.

2017 елның 17 июненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасында электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасына график җибәрелә.

3.10. Эксперт комиссиясе, проект яклау рәвешендә, грант алуга дәгъва кылучыларны сайлап алуның турыдан-туры этабын үткәрә.

3.11. «Иң яхшы методист» гранты тапшырыла:

рейтингта 1 дән 25 кә кадәр урын алган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре мәгариф бүлекләренең (идарәләренең) укыту-методик эш буенча башлык урынбасарларына;

рейтингта 1дән 25 урынга чыккан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре мәгариф бүлекләренең (идарәләренең) тәрбия эше буенча башлык урынбасарларына;

рейтингта 1дән 280 урынга чыккан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре мәгариф бүлекләре (идарәләре) методларыстларына.

3.12. Конкурс нәтиҗәләре буенча 2017 елның 27 июненә кадәр Эксперт комиссиясе тарафыннан грант алучылар исемлеге төзелә һәм раслана.

3.13. 2017 елның 30 июненә кадәр Грант бирүче грант алучыларның расланган исемлеген үзенең рәсми сайтында урнаштыра

## 4. Конкурсны финанслау

Грант бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

“Иң яхшы методист” грантын гамәлгә ашыру чараларының календарь Планы

| № п/п | Чара | Үтәлү срогы | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | “Иң яхшы методист” грантын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча оештыру комитеты киңәшмәсе | 2017 ел апрель | Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми беле бирү һәм укучыларның йомгаклау аттестациясе бүлеге |
| 2 | Мунисипаль берәмлекләрнең башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре белән киңәшмә | 2017 ел апрель | Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми беле бирү һәм укучыларның йомгаклау аттестациясе бүлеге |
| 3 | Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында Грант турында норматив-методик материаллар һәм реклама мәгълүматы урнаштыру | 2017ел май | Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми беле бирү һәм укучыларның йомгаклау аттестациясе бүлеге |
| 4 | Конкурста катнашырга теләүчеләрдән документлар кабул итү, электрон теркәлү, конкурс документларын карау | 2017 елның 31 маена кадәр | ТР Мәгарифне үстерү институты, Эксперт комиссиясе |
| 5 | Эксперт комиссиясе утырышы, нәтиҗәләр чыгару (йомгак ясау) | 2017елның 27 июненә кадәр | ТР Мәгарифне үстерү институты, Эксперт комиссиясе |
| 6 | Йомгаклау әмерен (боерыгын) чыгару | 2017елның 30 июненә кадәр | Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми беле бирү һәм укучыларның йомгаклау аттестациясе бүлеге |
| 7 | Грант алучыларга бер тапкыр бирелә торган Грант түләүне оештыру | 2017 ел август-сентябрь | Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми беле бирү һәм укучыларның йомгаклау аттестациясе бүлеге |